| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» 11 2022 ел № 321

2023 елга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары балаларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары балаларын йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2010 елның 5 июлендәге 545 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

- 2023 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативлары;

- балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә.

2. Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары нигезендә гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.С. Галимуллин